Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

1 апрель, 2020 ел № 65

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2021 елның 15 мартындагы гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында элегрәк кабул ителгән карарның үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары

белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов